ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» август 2022 ел № 169

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләрне чикләү турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 10 февралендәге 65 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләрне чикләү турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 10 февралендәге 65 номерлы карарына беркетелгән үзгәрешләрне расларга».
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) бастырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
от 01.08.2022 № 169
карары белән расланган

**Үзгәрешләр**
**«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында мәгариф өлкәсендә вәкаләтләр бүлешү турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 10 февралендәге 65 номерлы карарына**

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләрне чикләү турында» 2014 елның 10 февралендәге 65 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында мәгариф өлкәсендә вәкаләтләр бүлешү турында нигезләмәдә:

а) 2 бүлекнең 2.5, 2.6 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2.5. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесенең вәкаләтләрен билгеләү (раслау) һәм туктату, муниципаль мәгариф учреждениеләре директорларыннан тыш;
2.6. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе белән, муниципаль мәгариф учреждениеләре директорларыннан тыш, хезмәт шартнамәсен төзү һәм туктату;».

б) 3.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Мәгариф өлкәсендә кадрлар сәясәтен гамәлгә ашыру, муниципаль мәгариф учреждениесе директоры вазыйфасына билгеләп куелуны (раслауны), муниципаль мәгариф учреждениеләре директорларының вәкаләтләрен туктатуны, муниципаль мәгариф учреждениеләре директорлары белән хезмәт килешүләрен төзүне (туктатуны), педагогик һәм җитәкче кадрларны аттестацияләүне оештыру, муниципаль мәгариф учреждениесе директоры вазыйфасына конкурс процедураларын үткәрү.».